ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 сентября 2019г.

№ 4948

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ санлы Законы, Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 нче карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 нче, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 нче, 2017 елның 24 июлендәге 4318 нче, 2017 елның 25 сентябрендәге 5702 нче, 2017 елның 27 сентябрендәге 5755 нче, 2017 елның 23 ноябрендәге 7195 нче, 2017 елның 7 декабрендәге 7601 нче, 2018 елның 8 августындагы 4481 нче, 2018 елның 19 сентябрендәге 5336 нчы, 2018 елның 26 сентябрендәге 5567 нче, 2018 елның 16 ноябрендәге 6757 нче, 2018 елның 13 декабрендәге 7452 нче, 2019 елның 29 мартындагы 1612 нче, 2019 елның 10 июлендәге 3549 нчы карарлары редакциясендә) расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 бүлекнең III бүлекчәсендә:

- 7, 8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручылар | Үтәү срогы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 (база) | 2017 Кеше | 2018 Кеше | 2019 Кеше | 2017 (мең сум) | 2018 (мең сум) | 2019 (мең сум) |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Иҗтимагый оешмалар активистларына материаль стимуллаштыру ярдәме күрсәтү | Башкарма комитет | ел дәвамында | оешмалар саны | 9 | 9 | 9 | 9 | 357,6 Муниципаль бюджет | 345,0 Муниципаль бюджет | 483,4 Муниципаль бюджет |
| 8. | Элемтә хезмәтләреннән файдаланган өчен чыгымнарны компенсацияләү, иҗтимагый оешмаларның коммуналь түләүләрен түләү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ел дәвамында | оешмалар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 80,08 Муниципаль бюджет | 76,12 Муниципаль бюджет | 91,10 Муниципаль бюджет |

- «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы: | | | | | | | | 2610,78 | 2584,04 | 2941,9 |

3) 7 бүлекнең IV бүлекчәсендә:
- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Бөек Ватан сугышы ветераннарын, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, беренче төзүче ветераннарны календарь бәйрәмнәр белән котлау (23 февраль, 8 Март, 9 Май), шәһәр һәм республика үсешенә зур өлеш керткән юбилярларны (90, 95, 100 яшь һәм өлкәнрәкләр) котлау | Башкарма комитет | ел дәвамында | кеше саны | 300 | 300 | 300 | 300 | 0 | 0 | 352,1 Муниципаль бюджет |

- «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы: | | | | | | | | 1494,79 | 1580,8 | 1 804,1 |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                     Р.Ә. Абдуллин